**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Алан-Бексер, ул. Центральная,19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**26.02.2021 ел** **№4**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Кеше тормышының уңай шартларын уңайлату, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларына ия булучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Алан - Бәксәр авыл җирлеге Советының 2019 ел, 23 март 163 номерлы карары белән расланган “Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә халык алдында тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР бирә:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» гы карары проекты (алга таба – Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты) буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктларында әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык тыңлаулар үткәрү датасын, вакытын һәм урынын кушымта нигезендә расларга.

3. “Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә” үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү вакыты – 2021 елның 1 мартыннан 2 апреленә кадәр.

4. Әлеге карар нигезендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрүгә вәкаләтле орган булып Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл

җирлегенең “Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре” проектын әзерләү комиссиясе тора (алга таба – Комиссия).

5. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 ст. 12 өлеше нигезендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә кагылышлы идентификация узган ачык тыңлауларда катнашучыларның тәкъдимнәре һәм искәрмәләре Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан 2021 елның 02 апрелenә кадәр җирле үзидарә органнарының эш режимы кысалаарында, халык тыңлауларында катнашучыларның җыелышларын үткәрү барышында, экспозицияләрне карау вакытында, язма яки телдән кабул ителә.

6. Комиссия “Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» проектының эчтәлеге турында халыкка җиткерү максатыннан чыгып, “Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре”н раслау ту́рындагы карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү урынында (гавами тыңлаулар беркетмәсен алып бару урынында) күргәзмәләр, демонстрация материаллары экспозицияләрен оештыруны тәэмин итә.

7. Җирлектә яшәүчеләрдән һәм башка кызыксынган затлардан “Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре”н раслау турындагы карар проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кабул итү эш көннәрендә иртәнге 9 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча башкарыла: 422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк урамы, 19 йорт.

8. “Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре”н раслау турындагы карар проекты буенча җирлек халкыннан һәм башка кызыксынган затлардан искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кабул итү 02.04.20021 елның 16: 00 сәгатьтә туктатыла.

9. Комиссия авыл халкын һәм башка кызыксынган затларны «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре” проекты белән алданрак таныштыру максатларында:

“Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре” проектын Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Интернет" мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә рәсми сайтында урнаштыра;

Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында (Башкарма комитетның эш режимы нигезендә) җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты белән танышуга киртәләрсез керү мөмкинлеге булдыра.

10. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында» 27.01.2001 ел, № 1 карарын гамәлдән чыгарырга.

11. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

12. Карар рәсми халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә

13. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе З.Р.Гарифуллина

Кушымта

Расланган

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 26 феврале № 4 Карары белән

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү урыны, датасы, вакыты**

| № п/п | Населенный пункт/ место | Дата и время проведения |
|---|---|---|
| 1. | Алан-Бәксәр авылы - түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур, 19 йорт, Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы | 05.04.2021ел. 09.00 сәг.тә |
| 2. | Әсән авылы - түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Әсән авылы, С.Сәйдәшев ур, 5 Б йорты янындгы мәйданда | 05.04.2021ел 10.30 сәг.тә |
| 3. | Алат спиртзаводы авылы - түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алат спиртзаводы авылы, Үзәк ур, 33 йорт янындгы мәйданда | 05.04.2021ел 12.00 сәг.тә |
| 4. | Гәр авылы - түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Гәр авылы, Үзәк ур, 24 йорт янындгы мәйданда | 05.04.2021ел 13.30 сәг.тә |
| 5. | Шөмлән авылы - түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Шөмлән авылы, Үзәк ур, 1 йорт янындгы мәйданда | 05.04.2021ел 15.30 сәг.тә |